**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА МЕНЗЕЛИНСКА МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИНЗӘЛӘ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 02.09.2026

КАРАР
№ 401

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Береговая урамы, 12 нче йорт - «кунакханә хезмәте күрсәтү» индивидуаль торак йортлар төзелеше зонасында (Ж1) урнашкан, «16:28:180301:1163 кадастр номеры, 908 кв.м мәйданы булган җир кишәрлегенә шартлы рөхсәт ителгән кулланыш төрен бирү турында» проекты буенча ачык тыңлауларның билгеләнүе турында

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына, 06.10.2003 № 131-ФЗ санлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законына һәм Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына ярашлы, Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Береговая урамы, 12 нче йорт - «кунакханә хезмәте күрсәтү» индивидуаль торак йортлар төзелеше зонасында (Ж1) урнашкан, «16:28:180301:1163 кадастр номеры, 908 кв.м мәйданы булган җир кишәрлегенә шартлы рөхсәт ителгән кулланыш төрен бирү турында» проекты буенча ачык тыңлауларны уздыруны билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны оештыручы - коллегиаль киңәшләшү органы составын расларга:

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.А. Чухланцев;

Минзәлә муниципаль районының «Җир һәм мөлкәт палатасы» МКУ рәисе Р.С. Шакиров;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы урынбасары-баш архитектор Петров В.К.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы Басков Е. А.,

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының юридик сектор мөдире Петрова А.В.

3. Ачык тыңлауларны оештыручыга ачык тыңлауларны җирле үзидарә

турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Ачык тыңлауларны уздыру вакытын билгеләргә – 2026 елның 10 сентябреннән 2026 елның 18 сентябренә кадәр. Ачык тыңлауларны уздыру вакыты – 2026 елның 18 сентябре.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Шәйсуваров

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МЕНЗЕЛИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ * ОГРН 1061682001116 ИНН 1628006366 Исполнительный комитет города Мензелинска